КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 10 ноябрь г.Казань № 1060

Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә белем бирү, шәхси гомуми белем бирү оешмалары һәм индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлешенең 6 пунктын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә белем бирү, шәхси гомуми белем бирү оешмалары һәм индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин